КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 22 август

г.Казань

№ 881

Муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәдәге үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлау органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның айлык акчалата бүләкләү һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән расланган муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрендәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларның айлык акчалата бүләкләү күләмнәрен 2022 елның 1 октябреннән 1,04 тапкырга арттырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте

өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 ел, 28 март, 182 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен алар биләгән муниципаль хезмәт вазыйфалары нигезендә 2022 елның 1 октябреннән арттырырга.

3. Әлеге карарның 2 пункты нигезендә Татарстан Республикасында муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме белгеченең вазыйфаи оклады күләмен 1,04 мәртәбә индексацияләргә һәм аны 11 958 сум күләмендә билгеләргә.

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин